КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1249

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль,

568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь,1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 15 июль, 683 нче; 2022 ел, 12 август, 797 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2022 ел, 20 сентябрь, 1018 нче; 2022 ел, 11 октябрь, 1093 нче; 2022 ел, 8 ноябрь, 1184 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы бертип булмаган кайбер учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифасын биләгән, «Шәфкать туташы эше» әзерлек юнәлеше буенча бакалавриат бетергән югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 16 937 сум күләмендә билгеләнә.»;

4.2 пунктта «медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә» сүзләреннән соң «һәм «гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифасын биләүче хезмәткәрләренә» сүзләрен өстәргә;

1 нче таблицаның «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме» бүлегенә «, гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифалары» сүзләрен өстәргә;

3 нче таблицаның 1 графадагы «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» юлына «, гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифалары» сүзләрен өстәргә;

4 нче таблицаның «Һөнәри квалификация төркеме исеме» графасындагы «Урта медицина һәм фармацевтика белемле белгечләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме» юлына «, гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифалары» сүзләрен өстәргә;

17 нче таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифаларын биләүче хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме 45кә тигез.»;

6.4 пунктның 6.4.14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.14. Бала йортлары җитәкчеләренең база һәм вазифа окладлары, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База оклады, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент зурлыгы | Вазифа оклады, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 35 500 | 1,00 | 35 500 |
| 2 | 35 500 | 0,95 | 33 725 |
| 3 | 35 500 | 0,90 | 31 950 |
| 4 | 35 500 | 0,85 | 30 175 |
| 5 | 35 500 | 0,80 | 28 400 |
| 6 | 35 500 | 0,65 | 23 075 |

Бала йортлары җитәкчеләренең вазифа окладларын билгеләгәндә, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген, әлеге учреждениеләр эшчәнлеге үзенчәлекләрен исәпкә алып, вазифа окладына карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Вазифа окладына карата әлеге арттыру коэффициентын куллану компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазифа окладын барлыкка китерми.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы кайбер бертип булмаган учреждениеләрдә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 50 нче өстәмә түләү коды юлындагы 5 графада «4» санын «20» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин